**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"17" ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2021 елның 17 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән,тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 900 (тугыз йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Чишмәле Сап авылында скважина ремонты (бораулау ), килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыеның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 216 (ике йөз уналты) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан граҗданнар саны 133 (бер йөз утыз өч) кеше, бу 62 % тәшкил итә..

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 133 (бер йөз утыз өч) кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип таныргa.

2. "Сез 2022 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән,тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 900 (тугыз йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Чишмәле Сап авылында скважина ремонты (бораулау ), килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.